| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ СМАИЛЬСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>СМӘЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 сентябрь 2018ел. № 82

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарынын сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукынын топ гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законнын 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы," Смәел авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 сентябрендәге «Смәел авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» гы 81-нче номерлы карары, Смәел авыл җирлеге башкарма комитеты 18.09.2018 елгы карары нигезендә, Смәел авыл җирлеге Уставы нигезендә, Смәел авыл җирлеге Советынын 2018 нче елның 18 нче сентябрендә кабул ителгән "Смәел авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында" гы 81-нче номерлы карары № 13 - «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге Советы Смәел авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» карары:

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым

акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2019 елда Смәел авыл җирлегендә яшәүче 18 яше тулган, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 450 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:

Смәел авылында: Бауман урамында юлларның асфальт-бетон катламын норматив хәлгә китерү, М. Җәлил, Киров урамнарындагы юлларны ремонтлау;

Сизнер авылында Совет урамында балалар өчен уен мәйданчыгы, тротуар һәм периметр буенча коймалар урнаштыру, зиратка чүп-чар контейнеры алу һәм урнаштыру,зират территориясендә инвентарь саклау өчен бина төзү.

ӘЙЕ ЮК

3. Смәел авыл җирлеге Советы карары нигезендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаны экономияләү очрагында, экономияләнгән акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.

4. Әлеге карарны " Хезмәт» район газетасында һәм pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка хәбәр итәргә, baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга кирәк.

5. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Балтач муниципаль районы
Смәел авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Йосыпов